
Шәмсия
Җиһангирова
Балачак
кая
китә?



ШӘМСИЯ
ҖИҺАНГИРОВА

БАЛАЧАК КАЯ КИТӘ?

ШИГЫРЬЛӘР



КАЗАН ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ 1989

ББК 84(2Р-Тат)-5
Җ61

Художнигы
ЗИФА МӨХӘММӘТҖАНОВА

Җиһангирова Ш. Г.

Җ61 Балачак кая китә? : Шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.—31 бит.
ISBN 5—298—00158—0

Җ $\frac{4803010200—243}{М132(03)—89}$ 182—89

ISBN 5—298—00158—0 © Татарстан китап нәшрияты, 1989.

КЫЗЫМ БЕЛӘН УЛЫМ БАР

Кызым белән улым бар —
Ике бөртек нурым бар!
Кояштай көлеп кенә
Торам мин шуңа күрә.
Кызым белән улым бар —
Ике моңлы кылым бар!
Гел җырлап-биеп кенә
Яшим мин шуңа күрә.
Кызым белән улым бар —
Ике ярдәм кулым бар!
Эшләрем бара уңга
Минем һәрвакыт шуңа.

БӘБИ ТАКМАГЫ

Аппа-түк, аппа-түк,
Бәләкәй генә бер кәтүк!
Әле бары алтмышлы,
Бар белгәне ятмышлы,
Елашлы да көлешле,
Башка берни белмешле.

Аппа-түк, аппа-түк,
Булыр ул унлы кәтүк.
Сизми дә калырбыз кук,
Атлап китәр түк тә түк.
Авызы тулы теш булыр,
Акылы бик күп булыр.

Аппа-түк, аппа-түк!
Минем улым зур кәтүк!

УЛЫМ БӘБКӘ САКЛЫЙ

Үзе, нәни бәбкә кебек,
Әвеш-тәвеш атлый.
Тик сер бирми,
Чыбык тотып,
Улым бәбкә саклый.

Безнең бәбкәләр янына
Чит бәбкәләр килсә,
Чыбык селтәп уңга-сулга,
Куркыткандай итә.

Файдага ярый бит хәзер,
Йоклап кына ятмый!
Бәбкәне — улым,
Улымны
Дәү әнисе саклый.



САЛКЫН ТҮГЕЛ, ЯЛКЫН БАБАЙ

— Ай-һай усал, улым,
Салкын бабай!
Аякны-кулларны өшетә!
— Салкын түгел, әни,
Ялкын бабай:
Ул мине өшетми, эс-се-тә!

* * *

Бирделәр безгә бакчада
Карабодай боткасы.
Авызымда бал кебек
Эреде ул йотканчы.

«Нинди уңган кыз!» — диеп,
Тәлинкәм тора көлеп —
Мин юган кебек түгел,
Әнием юган кебек.

БӘХЕТ

Илдарның бит сеңлесе бар!
Йоклап китсә сеңлесе,
— Тсс! — ди Илдар сәгатьләргә,—
Шыпырт кына зеңлисе.
Тсс! — ди Илдар бал кортына,—
Тып-тын гына безлисе.
Тсс! — ди машиналарына,—
Тавыш-тынсыз йөрисе.
Тсс! — ди Илдар әнисенә,—
Ымлап кына сөйлисе.
Тсс! Очмагыз, самолетлар,
Йоклап киткән сеңлесе.
— Аңа зур үсәргә кирәк:
Күбрәк йокласын! — ди.
Уенчык белән уйната,—
Елаудан туктасын,— ди.—
Сеңлем шундый кечкенә,
Үзе шундый тәти! — ди.—
«Ән-нә» түгел, «әни» дип әйт,
«Әт-тә» түгел, «әти»,— ди.—
Аңа әле күлмәкләрен
Буяса да ярый,— ди.—
Мин гел чиста гына булам —
Мин бит инде абый,— ди...
Гел янында бөтерелә,
Һич кенә арып тормый.
Әллә ни бирәм дисәң дә,
Сеңлесен алыштырмый!

КЕЧКЕНӘ

— Әни, нигә безнең Гөлназ
Шулкадәрле кечкенә?
Минем егерме тешем бар,
Ә аныкы өч кенә.
Ә нигә соң аягында
Басып тора ул көчкә?
— Үсәр, улым! Синең кебек
Җитсен әле ул өчкә.
Бөтен бәбиләр дә шулай
Кечкенә була башта.
Син дә бик кечкенә идең
Без алып кайткан чакта...
— Мин аны күтәреп йөрим!
Үсмәсен — шулай торсын!
Әни! Син кечкенә чакта
Кечкенә идеңме соң?!

ӘНИ БУЛАСЫ КИЛӘ

Кызым инде зур үсте:
Матур күлмәкләр сорый,
Көне буе караса да,
Көзгедән бер дә туймый.
Чәчләрен әле тегеләй,
Әле болайга тарый.
Әле зәңгәр, әле кызыл
Күлмәген киеп карый.
Аның инде тиз-тиз генә
Әни буласы килә!
Мин кызыгып карап торам:
Бәби буласым килә...

КӨЛКЕ

— Улым! Нигә син
Һаман көләсең?
Зур бит инде син —
Гел-гел көләргә
Ярамаганны
Яхшы беләсең.

— Нишлим соң, әни,
Мине бит Көлке
Кытыклап тора:
Кызык булмаган
Чакта да һаман
Кызык таптыра.



БАЛАЧАК КАЯ КИТӘ?

— Балачакта мин дә, улым,
Синең кебек шук идем:
Шаярмаган да көлмәгән
Бер минутым юк иде.

— Балачагың кайда, әни?
Әллә калган авылда,
Әллә алырга оныттың
Монда килгән чагында?

Ярар, әни, борчылма син!
Зәңгәр ат җигеп кенә,
Иртәгә иртән үк торып,
Мин аны алып киләм.

Син аны бикләп куярсың
Ачкыч белән ныгытып.
Аннан инде калдырмассың
Беркайчан да онытып.


Йөртерсең аны янында
Иркәләп-сөеп кенә,
Аннан инде яшәрсең гел
Елмаеп-көлеп кенә!

ЗООПАРКТА

— Әнә тегендә маймыллар,
Менә монда тиеннәр,
Читлек эчендә тын гына
Йоклап ята бүреләр.

Әнә-әнә, ак аюлар,
Менә монда күрәне.
Тәвә кошы була инде
Тәти күлмәк кигәне.

Әнә теге — эти кеше,
Ә бусы — әни дөя...
— Гөлназ кызлары, әнием,
Юк соң аларның нигә?!



ИКЕ ТӨШ

— Әнием, бүген мин сине
Төшемдә күрдем төнлә.
Кулларны кулга тотышып,
Урамда йөрдек бергә.
Куышлы да, качышлы да,
Әбәкле дә уйнадык.
Көне буе чана шудык,
Салкын диеп тормадык.
Йөгереп төштек су буена —
Шудык тимераякта.
Хәлдән таеп, өйгә кайттык
Кояш баеган чакта.
Шунда безнең каршыбызга
Килеп чыкты дәү әни!
Ачуы килгән булса да,
Орышмады әллә ни...

Кинәт, Гөлназны бүлдереп,
Илдар кушылды сүзгә:
— Алдашма син, сеңлем, алай,
Дөресен генә сөйлә.
Әнием бит минем белән
Җиләкләр җыеп йөрде!
Синең төшеңдә түгел,
Ул
Минем төшемдә иде!

КАЙГЫРТУ

Бакчага бара Гөлназ,
Киенгән җылы итеп:
Өстендә калын пәлтә,
Аякта киез итек.

— Әнием,— ди,— кара әле,
Агачлар бит өшегән;
Җәй көне киенгән иде,
Кышка кергәч чишенгән.

Әнә бит ничек туңганнар,
Калтыранып торалар.
Минеке шикелле күлмәк
Бәйләп бир син аларга.

Бияләй дә, оекбаш та
Бәйләрсең бер тотынгач —
Аларның бит әнисе юк
Җәлләргә кызын, туңгач...

* * *

— Кара әле, улым,
Айның
Яртысы кая киткән?!


— Беләм, беләм!
Ярты айны
Лу-но-ход алып
Төшкән!

СЫЕРЧЫКЛАР КИЛГӘН

— Сыерчыклар килгән, әни!
Кара, ничек сайрыйлар.
Әнә ничек шатлананалар —
Алар мине таныйлар.

«Әниең белән икәүләп
Кая барасың? — диләр.—
Безнең янга менеп, әйдә,
Ял ит, аргансың»,— диләр...

Дөрес карамыйсың, әни!
Агачта түгел алар.
Әнә, әнә! Баганада,
Бауда эленеп торалар.



ЙОКЛЫЙСЫМ КИЛӘ

Кешеләр күптән
Йоклаган инде,
Машиналар да
Туктаган инде.
Уенчыкларым
Йоклыйлар күптән.
Тәти сеңлем дә
Бәү-бәүгә киткән.
Гөлләр дә төнлә
Су сорамыйлар:
Көн буе үсеп,
Бик тә арыйлар,
Күзләрен йомган
Чәчәкләре дә...
Дәү әниемнең
Әтәчләре дә,
Казлар, күркәләр
Йоклап киткәннәр
Инде авылда.
Миңа да кирәк
Йоклап алырга!
— Әни! Әнә бер
Самолет оча —
Миңа да тизрәк
Йокларга куша.
«Мин дә йокларга
Кайтып барам,— ди.—
Көн буе очып,
Мин дә арам»,— ди.

Күзләрем әйтә:
«Йокым килә»,— ди.
Телем дә: «Җитәр,
Әзрәк сөйлә»,— ди.
Аякларым да
Чабып арганнар:
Татлы йокыга
Китеп барганнар...
Киемнәрем дә
Ял итә чөйдә...
Минем дә... бик-бик...
Йоклыйсым... ки...лә...

БҮРЕК ТАПТЫМ

Ур-ра, ур-ра! Бакчада
Бүген мин бүрек таптым.
Җәй көне кем бүрек кия?
Кем югалткан? —
Шаккаттым.

Чакырдым әниемне,
Чакырдым әтиемне.
— Бүрек,— дидем,— бүрек таптым!
Тизрәк килегез инде!
Килеп күрегез инде!

Мин кычкырган тавышка
Селкенеп куйды... бүрек —
Куян булган икән бит ул —
Күзем ачып йомганчы
Очып китте ук кебек.

ТАМАША

Килеп кердем бәйрәмгә
Уен кызган чагында —
Кыш бабай һәм кунаклар
Бии чыршы янында.
Тиен, болан, аюлар,
Бүре, керпе һәм төлке...
Куян булып киенгәне
Нәкъ менә чып-чын төсле.
Кыш бабай да яраткан —
Бүләк бирде үзенә.
Бигрәк шаян икән инде! —
Колакларын селкетеп
Чабып китте тиз генә.
...Битлеген салган иде —
«Кем?» — дип йөзенә бактым.
Менә сиңа т а м а ш а! —
Сеңлем икән! Шаккаттым!

БУРАТИНО

Бер курчагым бар минем.
Исеме Бу-ра-ти-но!
Көн дә үсә дәү борыны —
Төшенәлмим рәтенә!
Сораган идем әнидән,
— Белеп кал, — диде, — кызым,
Буратиноның борыны
Юынмаганга озын.
Су буена йөгердем мин,
Борыным үсмәс борын.
Юдым сабын беткәнче —
Үсә күрмәсен борын!

МӘЧЕ АЛДЫК!

Күршеләрдән күрмәкче
Алдык без дә бер мәче.
«Йомшак» дип исем куштык,
Башланды безнең дуслык.
Карап чыкты бөтен җирне —
Өстәл, диван асларын...
Аеруча нык ошатты
Әтиемнең башмагын.
Иснәп-ялап та карады,
Этеп-төртеп тә йөртте.
Бер дә аптырап тормады —
Эченә кереп китте.
Тегеләй дә болай итеп
Торды да боргаланып,
Ятты аннары эченә,
Йомгактай йомарланып.
Йоклап алгач, савытыннан
Тәмләп кенә сөт эчте.
Як-ягына каранды да
Өстәлгә менеп китте.
Аквариумнан, үрелеп,
Балык тотмакчы булды,
Тотып алып тиз-тиз генә
Кабып йотмакчы булды.
Барып чыкмагач бу эше,
Салындырып мыегын,
«Ни эшләргә соң?» — дигәндәй,
Торды бераз боегып.
Ялады аннары, килеп,
Әниемнең кулларын.
Идән буйлап куып йөртте
Дәү әнинең йомгагын...

Көне буе бертуктаусыз
Көлдерде дә көлдерде.
Үзенең безгә кирәклеген
Әнә шулай белдерде!

КЕМ ХАКЛЫ?

Аңламассың бу зурларны —
Алдыйлармы, чын сүзме? —
Төрлесе төрлечә дәшеп
Аптырата үземне.

Әти әйтә: «Зур улым», — ди,
Әни әйтә: «Бәбием», —
Апа әйтә: «Үскәнем», — ди,
«Җимешем», — ди әбием.

Ә бабам әлеге эштә
Барыннан да уздыра —
Кайтып керсәм, «Нихәл, картлач», —
Дип миңа кулын суза.

ЧИТЕН МӘСЬӘЛӘ

Хикмәте соң нәрсәдә?
Аңламыйм бернәрсә дә:
Ничек кенә чишсәң дә,
Чишелми бит мәсьәлә.
Абыйга әйткән идем,
— Тап,— ди,— башта төенен.
Дикъкать белән мәсьәләне
Кабат укы син, энем.
Укыйм:
«Өстәл тирәли утырган
Мәче, маэмай һәм Барый.
Ничә аяк һәм ничә кул? —
Кайсыгыз дөрес саный?
Бер шарты бар: аякларны
Сана өстәл астыннан,
Кулларны сана өстеннән —
Ничә булыр барысына?»
Өстәл астыннан санасаң:
Барыйда аяк — ике,
Ике аяк мәчедә дә,
Маэмайныкы да — ике.
Өстәл өстеннән санасаң:
Барыйда бар ике кул.
Мәчедә дә, маэмайда да,
Һәркемдә дә ике ул.
Бергә кушкач?..
Аяклар да, куллары да алтышар!
Китапның артында ләкин
Башкача җавабы бар.

Анда әйткән: «Һәммәсенә
Ике аяк, ике кул».
Аңламыйм, берни аңламыйм!
Нигә алай була ул?!
Нишләргә соң, нишләргә?!
Чишелми бит мәсьәлә...

2

Озын-озак уйлый торгач,
Шундый карарга килдем:
Күршедән маэмае белән
Азатны алып кердем.
Аерым-аерым урындыкка
Утырды икесе дә.
Үзебезнең мәчебезне
Утырттым өченчегә.
Ә үзем өстәл астына
Төштем дә аяк эзлим —
Азат аягыннан башка
Бернинди аяк күрмим.
Өстәл өстендә дә бары
Азат куллары гына...
Ии-хх!
Яхшылап укырга кирәк
булган соравын гына...

Менә шулай мәсьәләнең
Ачылды бөтен сере.
Сез ул серне әллә кайчан
Төшендегез билгеле!

КОРАБ КИЛӘ

Диңгез буйлап
Кораб килә.
Миңа таба
Карап килә.
Ә мин торам
Ярда басып,
Йөрәк тибә,
Ярсып-ярсып.
Очам хыял
Канатында —
Туктар микән
Кораб монда?!
Китәр микән
Мине алып
Мин ачасы
Җир чатына?
Бардыр әле,
Бардыр анда
Ачылмаган
Яңа җирләр!..
Китеп барсам,
Бик кайгырыр,
Бик еларлар шул
Әниләр.
Маэмаем да,
Мине сагынып,
Өрер-елар,
Һич туктамас.
Кайгысыннан
Мәче хәтта
Сукыр тычкан да
Тоталмас.

Сеңлем дә
Елар әле,
Китеп барсам
Сәяхәткә.
Болай гына
Үчекли ул,
Кычкырыша,
Бәхәсләшә.
Китеп барсам,
Мәктәбем дә,
Эшен ташлап,
Торыр елап...
Китмим, китмим,
Болай булгач!
Ярда калам,
Кулым болгап.
Чү! Нәрсә бу?
Кораб кинәт
Су астына
Төшеп китте.
Һарап булды,
Болай булгач,
Юкка чыкты,
Батты, бетте...
Тукта! Тукта!
Су өстенә
Калкып чыкты
Кой-йы-ры-гы.
Коткарам мин
Аны үзем —
Җитсен генә
Кый-йу-лы-гым...

Куркак диеп
Уйламагыз,
Куркак түгел
Мин тумыштан.
Кереп киттем
Яланаяк —
Диңгез ул
Безгә тубыктан.
Мине күреп,
Кораб кинәт
Очып китте,
Канат җилпеп...
Кайтыйм инде
Чәй эчәргә,
Арганнардыр,
Мине көтеп...
Каян килсен
Монда диңгез?! —
Инеш шул
Диңгез дигәне.
Корабы да
Кораб түгел —
Дәү әниемнең
Үр-дә-ге!

Мин бит шулай
Көн дә иртән
Су буйларын
Урап кайтам:
Кызык уйлап
Чыгарырга,
Хыялланырга
Яратам!

КЫРГАЯКТА НИЧӘ АЯК?

Баскыч башына басып
Уйланып тора идем,
Әниемне сагынып,
Моңланып тора идем;
Дәү әнием күргән дә
Килеп чыкты яныма.
— Нишләп торасың? — дигәч,
Дидем: «Тиктомал гына».
— Алай тиктомал гына
Торма,— ди дәү әнием,—
Ялкау малай булып син
Куя күрмә, бәбием.
Ялкау гына тик торыр,
Тик утырыр, тик ятыр.
Бер дә булмаса, улым,
Тун итәгең уа тор.
Әллә инде дәү әни
Саташа башлаганмы?
Урамда җәй икәнен
Онытып ташлаганмы?
Әйткәч, никтер, елмаеп
Торды да миңа карап:
— Алайса сөң сана,— ди,—
Кыргаякта ничә аяк?
— Каян табыйм? — дигәчтен,
— Эзлә,— ди,— таш астыннан,
Абзарда да булыр ул,
Мунчада да бар сыман...
Эзләнеп йөри торгач,
Кешедән сорый торгач,
Таптым икенче көнне
Сәгать унике тулгач.

Әй, тотындым санарга!
Санадым да санадым,
Санадым да санадым...
Йөзне узгач буталдым,
Шул урында туктадым...
Дәү әнием сүзләренең
Серенә тиз төшендем —
Кырык аяк үзендә ул
Ялкау булган кешенең.
Кырык аяк кырык яктан
Бетәләр дә чуалып,
Урыныннан китә алмый
Ялкау кеше кузгалып.
Кыргаяк аякларын
Берәр санап караса,
Кырык аяк чире йокмый
Ул кешегә һичкайчан.

Әгәр эш тапмасагыз,
Ялкауланып ятмагыз —
Сез дә санап карагыз:
Кыргаякта ничә аяк?!

* * *

Киеп яңа тимераяк,
Алып Акбаен,
Шугалакка йөри Фәрит
Якшәмбе саен.
Артыннан чапкан Акбайны
Ул бик кызгана.
— Әтием,— ди,— тимераяк
Алыйк без аңа.

АБЫЙ БУЛДЫМ

Шатлык артты, шатлык миндә!
Сеңелем бар. Абый мин дә!
Күзе борчак кебек кенә.
Үзе курчак кебек кенә,
Кеп-кечкенә борыны да,
Авызы да уймак кына.
Тик хәзергә аның белән
Булмый әле уйнап кына.
Елап ала кайчагында
«Эм-мә, эм-мә» диеп кенә,
Йоклап китә үзе бик тиз,
Әни сөтен имеп кенә.
Иреннәрен бөрештереп,
Сөйләшергә азаплана.
Читтән генә карап торам,
Түзеп торам, яратсам да.
Әни әйтә: «Аны кулга
Өйрәтергә ярамый,— ди.—
Аннары гел күтәртә ул,
Бернигә дә карамый»,— ди.
Күрше әби, кергән саен,
Гел үчекләп кенә тора:
«Сатыгыз сез миңа шушы
Елак кызны»,— дигән була.
Сынар өчен, юри генә
Сөйлидер ул андый сүзне.
Бирәсем юк беркемгә дә
Шундый тәти сеңелемне!

КЕМГӘ НӘРСӘ

Бурап-бурап карлар ява —
Күз ачкысыз урамда.
Тәрәзәдән карап тора
Ике кеше буранга.

Малай:
— Әни!
Карлар төшә, карлар төшә —
Бөтен җир тулыр инде!
Чана шуарга урамда
Таулар да булыр инде.

Әнисе:
— Улым!
Карлар төшә, карлар төшә —
Авылда явар микән?
Уҗымнарга салкын тияр —
Кырларда кар бар микән?!


СӘБӘБЕН БЕЛДЕ


— Әби! Әби! Әбием! — дип,
Лилия өч эндәшә.
Әбисе һаман ишетми,
Сөйләшә дә сөйләшә.

Кычкыра шунда Лилия:
— Эндәшәм, — ди, — бишбылтыр,
Ә син, әбием, ишетмисең,
Әллә колагың сукыр?

КАРЛЫ СӨТ

Дәү әниемнең сыеры
Бирә җылы, парлы сөт.
Мороженое ашаса,
Бирер иде карлы сөт!





КАРА ТАБА

Кара! Кара!
Кара таба
Китеп бара
Мичкә таба.
Таба эче
Коймак кына!
Ә мичтә ут
Дөрләп тора.
Күзем алмый
Карап торам,
Коймакларны
Санап торам.
Тиздән коймак
Пешеп чыгар,
Кара таба
Мичтән чыгар!
Гел әнием
Тирәсендә
Бөтереләм
Мин дә шуңар!

ТИЗРӘК ҮСӘСЕМ КИЛӘ

Фәрит абый кебек, минем
Солдат буласым килә:
Башыма фуражка киеп,
Сакта торасым килә.

Йә булмаса, эти кебек,
Йортлар төзергә иде.
Шофер булып, машинада
Выжлап йөрергә иде.

Әйтәсез дә: «Чү, ашыкма,
Бераз сабыр ит әле.
Барына да өлгерерсең,
Башта син зур үс әле».

Көтәм инде.
Миңа быел
Бары биш кенә тула.
Нигә икән бу балачак
Бигрәк озак була?!

ЭЧТӘЛЕК

Кызым белән улым бар 3
Бәби такмагы 3
Улым бәбкә саклый 4
Салкын түгел, Ялкын бабай 5
«Бирделәр безгә бакчада...» 5
Бәхет 6
Кечкенә 7
Әни буласы килә 7
Көлке 8
Балачак кая китә? 9
Зоопаркта 10
Ике төш 11
Кайгырту 12
«Кара әле, улым...» 12
Сыерчыклар килгән 13
Йоклыйсым килә 14
Бүрек таптым 15
Тамаша 16
Буратино 16
Мәче алдык 17
Кем хаклы? 18
Читен мәсьәлә 19
Кораб килә 21
Кыргаякта ничә аяк? 24
«Киеп яңа тимераяк...» 25
Абый булдым 26
Кемгә нәрсә 27
Сәбәбен белде 27
Карлы сөт 28
Кара таба 29
Тизрәк үсәсем килә 30

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

Джигангирова Шамсия Гатуфовна

КУДА УХОДИТ ДЕТСТВО?

Стихи

(на татарском языке)

Редакторы *М. Фәйзуллина*
Художество редакторы *Ф. Хәсьянова*
Техник редакторы *Г. Шәрифуллина*
Корректоры *Р. Хәмидуллина*

ИБ № 5293

Җыярга тапшырылды 24.01.89. Басарга кул куелды 7.07.89. Форматы $60 \times 90^1/_{16}$. Типография кәгазе № 1. Школьная гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 2,0. Шартлы буяу-оттиск 5,0. Нәшер-хисап табагы 1,49. Тиражы 20 000 экз. Заказ З-43. Бәясе 10 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420084, Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. 420084, Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084, Казан, Бауман ур., 19.




10 тиен